# КАРАР

2019 елның 28 ноябре, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 26 ноябрендә үткән гражданнар җыены беркетмәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча:

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылы территориясендә теркәлгән көндезге бүлектә укучы студентлар(курсантлар), I төркем инвалидлар, 18 яше тулмаган дурт яки аннан да артык күп балалы гаиләләр, ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:
--Ятмас Дусай авылы, Үзәк, Ятмас Дусай урамнарындагы вак таш җәелгән юлларга чокырлар ямау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
-Ятмас Дусай авыл җирлеге авылларында юлларны кардан чистарту;
- Ятмас Дусай авылында күперне ремонтлау;
- Ятмас Дусай авылы фельдшер-акушерлык пункты каршында вак таш җәю һәм торба салу ;
Ятмас Дусай авылы Узек урамында янгын гидрантын сатып алу hем урнаштыру, проект-смета документациясен эшкерту hем технадзорны тормышка ашыру эшләрен башкаруга юнәлтүгә ризамы ?:
« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 225 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 144 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гранданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 144 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылы территориясендә теркәлгән көндезге бүлектә укучы

студентлар(курсантлар), I төркем инвалидлар, 18 яше тулмаган 4 яки аннан да артык күп балалы гаиләләр, ялгыз аналар, 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

-Ятмас Дусай авылы, Үзәк, Ятмас Дусай урамнарындагы вак таш җәелгән юлларга чокырлар ямау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;

-Ятмас Дусай авыл җирлеге авылларында юлларны кардан чистарту.;

- Ятмас Дусай авылында күперне ремонтлау;

- Ятмас Дусай авылы фельдшер-акушерлык пункты каршында вак таш җәю һәм торба салу ;

Ятмас Дусай авылы Узек урамында янгын гидрантын сатып алу һем урнаштыру, проект-смета документациясен эшкерту һем технадзорны тормышка ашыру эшләрен башкаруга юнәлтүгә

« РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән.

3. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылып, гражданнар Җыенының нәтиҗәсен игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас Дусай Авылы Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина